| МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ |
| --- | --- |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

15.01.2016 ел Казан ш. № 1/2-пр

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2016 елның 24 мартында теркәлде, № 3246

БОЕРЫК

**2016 елга Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан алына торган средстволар хисабына субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында**

“Нәселле терлекчелеккә ярдәм итүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү турында” 4 декабрь, 2012 ел, № 1257, “Сарыклар һәм ана кәҗәләрнең, төньяк боланнарының марал һәм ит өчен көтү атларының баш санын арттыру буенча чыгымнарның бер өлешен каплауга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү турында” 4 декабрь, 2012 ел, № 1258, “Үсемлекчелекнең аерым кече тармакларын үстерүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында” 12 декабрь, 2012 ел, № 1295, “Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына үзләре җитештереп саткан һәм (яки) үзләре эшкәрткән сөтнең бер килограммына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында” 22 декабрь, 2012 ел, № 1370, “Авыл хуҗалыгын иминиятләштерүе килешүләре буенча иминиятләштерү премияләрен түләүгә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында” 22 декабрь, 2012 ел, № 1371, “Үсемлекчелек өлкәсендә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә бәйле булмаган ярдәм күрсәтүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында” 27

декабрь, 2012 ел, № 1431 Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларын үтәү йөзеннән боерык бирәм:

1. Расларга:

1.1. 2016 елда үсемлекчелек өлкәсендә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә бәйле булмаган ярдәм күрсәтүгә федераль бюджеттан средстволар хисабына субсидияләр бирү тәртибен (№ 1 кушымта);

1.2. 2016 елда сатып алынган элита орлыклары буенча авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре чыгымнарының бер өлешен каплауга федераль бюджеттан субсидияләр бирү тәртибен (№ 2 кушымта);

1.3. 2016 елда күп еллык җимеш һәм җиләк куакларын, интенсив типтагы бакчаларны утырту һәм карау буенча авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре чыгымнарының бер өлешен каплауга федераль бюджеттан субсидияләр бирү тәртибен (№ 3 кушымта);

1.4. 2016 елда файдаланудан төшеп калган иске бакчаларны агач-куаклардан чистартуга һәм чистартылган мәйданнарны рекультивацияләүгә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре чыгымнарының бер өлешен каплауга федераль бюджеттан субсидияләр бирү тәртибен (№ 4 кушымта);

1.5. 2016 елда үзләре җитештереп саткан һәм (яки) үзләре эшкәртүгә төяп озаткан сөтнең бер килограммына авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре чыгымнарының бер өлешен каплауга федераль бюджеттан субсидияләр бирү тәртибен (№ 5 кушымта);

1.6. 2016 елда сарыклар һәм ана кәҗәләрнең баш санын артыру буенча авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре чыгымнарының бер өлешен каплауга федераль бюджеттан субсидияләр бирү тәртибен (№ 6 кушымта);

1.7. 2016 елда нәселле терлекчелеккә ярдәм итүгә федераль бюджеттан субсидияләр бирү тәртибе (№ 7 кушымта);

1.8. 2016 елда авыл хуҗалыгын иминиятләштерү килешүләре буенча иминиятләштерү премияләрен түләүгә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре чыгымнарының бер өлешен каплауга федераль бюджеттан субсидияләр бирү тәртибен (№ 8 кушымта).

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

дәүләт ярдәмен алучы Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының авыл хуҗалыгы җитештерүне алып бару урыны буенча Татарстан Республикасы муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә (алга таба – Идарә) авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш) финанс-икътисадый торышы турында хисапны түбәндәге срокларда тапшыруны:

квартал тәмамланганнан соң 20 календарь көне эчендә;

ел тәмамланганнан соң 60 календарь көне эчендә.

Идарә Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең финанс-икътисадый торышы турында җыелма хисап тапшыруын;

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан финанс–икътисадый торышы турында хисап тапшырылмаганда, Министрлыкның дәүләт ярдәме чараларын күрсәтүне туктатып торуын.

3. Документлардагы мәгълүматларның дөреслеге, бюджет һәм кредит средстволарыннан максатчан һәм нәтиҗәле файдалану өчен җаваплылыкны субсидия алучы оешмаларның җитәкчеләренә һәм баш бухгалтерларына, Идарә начальникларына һәм Идарәләрнең финанс-икътисадый бүлекләре начальникларына йөкләргә.

4. Министр урынбасарларына, бүлекләр начальникларына, бу боерыкның 1 пунктында расланган Тәртипкә туры китереп, белгечләр тарафыннан документлар кабул итүне оештырырга.

5. Финанслау бүлеге начальнигына тиешле субсидияләр түләүне тәэмин итәргә.

6. Министрлыкның түбәндәге боерыкларын үз көчен югалткан дип танырга:

“2015 елга Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан алынучы средстволар хисабына субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” 15.01.2015 ел, № 3/2-пр;

“2015 елга Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан алынучы средстволар хисабына субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” 15.01.2015 ел, № 3/2-пр Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында” 17.02.2015 ел, № 23/2-пр;

“2015 елга Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан алынучы средстволар хисабына субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” 15.01.2015 ел, № 3/2-пр Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында” 17.02.2015 ел, № 23/2-пр-а;

“2015 елга Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан алынучы средстволар хисабына субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” 15.01.2015 ел, № 3/2-пр Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында” 12.03.2015 ел, № 36/2-пр;

“2015 елга Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан алынучы средстволар хисабына субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” 15.01.2015 ел, № 3/2-пр Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында” 06.06.2015 ел, № 96/2-пр;

“2015 елга Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан алынучы средстволар хисабына субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” 15.01.2015 ел, № 3/2-пр Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында” 11.06.2015 ел, № 127/2-пр;

“2015 елга Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан алынучы средстволар хисабына

субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” 15.01.2015 ел, № 3/2-пр Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында” 17.08.2015 ел, № 194/2-пр;

“2015 елга Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан алынучы средстволар хисабына субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” 15.01.2015 ел, № 3/2-пр Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында” 01.09.2015 ел, № 205/2-пр;

“2015 елга Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан алынучы средстволар хисабына субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” 15.01.2015 ел, № 3/2-пр Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында” 25.09.2015 ел, № 223/2-пр;

“2015 елга Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан алынучы средстволар хисабына субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” 15.01.2015 ел, № 3/2-пр Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында” 23.11.2015 ел, № 263/2-пр.

7. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары Н.Л.Титовка йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Премьер-министры урынбасары – министр М.Г.Әхмәтов**

ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
министрлыгының 15.01.2016 ел, № 1/2-пр
боерыгына № 1 кушымта

**2016 елда үсемлекчелек өлкәсендә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә бәйле булмаган ярдәм күрсәтүгә федераль бюджеттан средстволар хисабына субсидияләр бирү тәртибе**

1. Бу Тәртип, авыл хуҗалыгы культуралары чәчүлек мәйданының бер гектары исәбеннән, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш) федераль бюджет средстволары хисабына үсемлекчелек өлкәсендә бәйле булмаган ярдәм күрсәтүгә субсидияләр (алга таба – субсидияләр, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре, субсидияләр алучылар) бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр алуга авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләрен сайлап алуның критерие булып үсемлекчелек продукциясен җитештерү һәм сату тора.

3. Субсидияләр бирү шарты булып 2016 елда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең милкендә, аренда шартларында авыл хуҗалыгы культураларының чәчүлек мәйданнарына ия булуы тора.

4. Арбитраж суд тарафыннан субсидияләр алучыларга карата бөлгенлеккә төшү турында эш кузгатылганда, алар (алучылар) бу хакта, эш кузгатылган көнне, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) язмача хәбәр итәргә тиеш.

Субсидияләр үзләренә карата арбитраж суды тарафыннан бөлгенлеккә төшү тарафыннан эш кузгатылган авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә бирелми.

5. Субсидияләр бирүне максатлары булып тора:

чәчүлек мәйданының бер гектары исәбеннән, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең агротехник эшләр комплексын үткәрүгә чыгымнарының бер өлешен каплау;

авыл хуҗалыгы җитештерүенең экологик иминлеген арттыру;

туфракның уңдырышлылыгын һәм сыйфатын яхшырту.

6. Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре өчен субсидияләр күләме чәчүлек мәйданының бер гектары өчен түбәндәге формула буенча исәпләнелә:

$$У=П \times (183{,}0 + (2{,}7 \times У)+(60{,}5 \times И_{ппмр})),$$

биредә:

V – күчерү өчен субсидияләр күләме сумнарда;

П – 2015 елга уңыш җыю турында рәсми статистика хисабын (алга таба – уңыш җыю йомгаклары буенча мәгълүмат) булдыруга нигез итеп алынган, факттагы чәчүлек мәйданнары турында мәгълүмат белән расланган чәчүлек мәйданы, гектарда;

183,0 – чәчүлек мәйданының бер гектарына минималь ставка сумнарда;

2,7 – җитештерелгән ашлык берәмлегенең бер центнерны ставка, сумнарда;

У – бу Тәртипкә № 2 кушымта нигезендә, күчерү коэффициентларына туры китереп исәпләнгән уңыш җыеп алу йомгаклары турында мәгълүмат буенча чәчүлекләрнең бер гектарыннан алынган ашлык берәмлегенең центнерларда чагылдырылган авыл хуҗалыгы культураларының уртача уңышы;

60,5 – җирләрнең уңдырышлылыгы буенча чәчүлекләрнең бер гектарына уртача ставка, сумнарда;

Ищшр – бу Тәртипкә № 1 кушымта нигезендә, “Татарский” агрохимия хезмәте үзәге” Федераль дәүләт бюджет учреждениесе һәм “Альметьесвкая” агрохимия хезмәте станциясе” Федераль дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – агрохимхезмәтләр) тарафыннан тапшырылган мәгълүматлар нигезендә билгеләнгән, Татарстан Республикасы муниципаль районы буенча туфракның уңдырышлылыгының уртача индексы.

1. Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре субсидия алу өчен, бу Тәртипнең 6 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының муниципаль районнарындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренә (алга таба Идарә) түбәндәге документларны тапшыра:

түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр алуга гариза;

урып-җыю йомгаклары турында мәгълүмат;

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча, тиешле субсидияләр турында белешмә-исәпләмә;

милектә, арендада яки башкача законлы нигездә авыл хуҗалыгы культураларының чәчүлек мәйданнарына ия булуны раслаучы документлар;

Тапшырылган документларның күчермәләре авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан раслана.

2. Идарәләр:

а) субсидияләр алуга гаризаларны, алынган көнне, журналда терки, журнал битләренә номер сугылган һәм тегелгән, мөһер белән расланган, беркетелгән булырга тиеш;

б) бу Тәртипнең 6 пункты нигезендә тапшырылган документларны карап тикшерә. Документларны карап тикшерү срогы – гариза теркәтүгә алынганнан соң 15 эш көне;

в) әлеге документлар нигезендә, Министрлык тарафыннан расланган форма буенча Татарстан Республикасы муниципаль район буенча тиешле субсидияләр турында җыелма белешмә-исәпләмәләр төзи һәм Министрлыкка 2 эш көне эчендә тапшыра.

Субсидия бирүдән баш тартуга нигезләр булып тора:

документларны тулысынча тапшырмау;

документларда тулы булмаган, ялган мәгълүматларның булуы;

бюджет йөкләмәләре лимитының булмавы.

3. Министрлык бюджет средстволарын баш бүлүче булып тора һәм Федераль казначылык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган үзенең лицевой счетыннан, 3 эш көне эчендә, акча средстволарын күчерүне хәл итә.

Министрлык, Министрлык тарафыннан расланган форма буенча субсидия бирү турында килешү (алга таба – Килешү) төзи, анда субсидияләр бирүнең мәҗбүри шарты булып алучыларның Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контрольлеге органнары тарафыннан субсидияләр алучыларның субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерүгә ризалык бирүе тора.

Субсидияләр күчерүгә нигез булып Идарәләр тарафыннан Министрлыкка тапшырылган җыелма белешмә-исәпләмәләр тора. Идарәләр бюджет средстволары алынганнан соң биш эш көне эчендә субсидияләрне авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләрнең расчет счетларына күчерә.

10. Бирелгән субсидияләр, бу Тәртиптә билгеләнгән аларны бирү максатларын һәм шартларын бозу, субсидияләрне максатчан файдаланмау яки субсидияләр алу өчен ялган мәгълүматлар һәм документлар тапшыру очраклары ачыкланганда, Министрлык таләбе алынганнан соң 60 көн эчендә федераль бюджет keremenә кире кайтарылырга тиеш.

11. Субсидияләр алу турында килешүләрдә күздә тотылган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр калдыклары субсидияләр алучылар тарафыннан, субсидияләр бирелгән елдан соң килгән елның 1 декабренә кадәр, федераль бюджет керемена кире кайтарылырга тиеш.

12. Бу Тәртипнең 10 һәм 11 пунктларында күрсәтелгән бюджет средстволарын федераль бюджет керемена ихтыярый рәвештә кире кайтарудан баш тарту очрагында, алар, закон нигезендә, мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.

13. Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контрольлеге органнары авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

14. Идарәләр тарафыннан Министрлыкка тапшырыла торган һәм авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан Идарәгә тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык аларның җитәкчеләренә һәм баш бухгалтерларына йөкләнә. Закон бозучыларга карата закон нигезендә күздә тотылган җаваплылык чаралары кулланыла.

15. Бюджет средстволарыннан максатчан файдалануга Министрлык контрольлек итә.

2016 елда үсемлекчелек өлкәсендә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә бәйле булмаган ярдәм күрсәтүгә федераль бюджеттан средстволар хисабына субсидияләр бирү тәртибенә № 1 кушымта

**Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләрне субсидияләр күләмен исәпләү өчен туфракның уңдырышлылыгы индексы**

| № п/п | Татарстан Республикасы муниципаль районнар атамасы | Уртача күрсәткечләр | | | | | | | | Индекслар суммасы графа 4+ графа 6+ графа 8+ графа 10 | Туфракның уңдырышлылыгының уртача индексы графа 11/4 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | P205 | | K20 | | гумус | | Кислоталылыгы (ph) | | | |
| | | Микъдары, мг/кг | ТР индексы күрсәткече/ район күрсәткече | Микъдары, мг/кг | ТР индексы күрсәткече/ район күрсәткече | Микъдары, мг/кг | ТР индексы күрсәткече/ район күрсәткече | Микъдары, мг/кг | ТР индексы күрсәткече/ район күрсәткече | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 1 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| 1 | Әгерҗе | 132,1 | 1,0204 | 127,0 | 1,0731 | 3,3 | 1,3758 | 5,6 | 0,9982 | 4,4674 | 1,1169 |
| 2 | Азнакай | 136,0 | 0,9911 | 148,0 | 0,9208 | 6,6 | 0,6879 | 5,9 | 0,9475 | 3,5473 | 0,8868 |
| 3 | Аксубай | 115,3 | 1,1690 | 130,4 | 1,0451 | 5,6 | 0,8107 | 5,3 | 1,0547 | 4,0796 | 1,0199 |
| 4 | Актаныш | 142,2 | 0,9479 | 131,3 | 1,0379 | 6,2 | 0,7323 | 5,6 | 0,9982 | 3,7163 | 0,9291 |
| 5 | Алексеевск | 109,3 | 1,2332 | 138,4 | 0,9847 | 5,3 | 0,8566 | 5,5 | 1,0164 | 4,0909 | 1,0227 |
| 6 | Әлки | 126,0 | 1,0698 | 110,0 | 1,2389 | 4,4 | 1,0318 | 5,4 | 1,0352 | 4,3757 | 1,0939 |
| 7 | Әлмәт | 134,0 | 1,0059 | 132,0 | 1,0324 | 5,9 | 0,7695 | 5,8 | 0,9638 | 3,7716 | 0,9429 |
| 8 | Апас | 164,6 | 0,8189 | 159,1 | 0,8566 | 4,2 | 1,0810 | 5,6 | 0,9982 | 3,7546 | 0,9387 |
| 9 | Арча | 141,1 | 0,9553 | 134,8 | 1,0110 | 2,9 | 1,5655 | 5,4 | 1,0352 | 4,5670 | 1,1417 |
| 10 | Әтнә | 140,9 | 0,9566 | 112,5 | 1,2114 | 2,5 | 1,8160 | 5,5 | 1,0164 | 5,0004 | 1,2501 |
| 11 | Баулы | 100,1 | 1,3466 | 117,3 | 1,1618 | 6,5 | 0,6985 | 5,9 | 0,9475 | 4,1543 | 1,0386 |
| 12 | Балтач | 132,7 | 1,0157 | 127,6 | 1,0680 | 3,3 | 1,3758 | 5,7 | 0,9807 | 4,4402 | 1,1101 |
| 13 | Бөгелмә | 133,5 | 1,0097 | 142,2 | 0,9584 | 7,1 | 0,6394 | 5,9 | 0,9475 | 3,5549 | 0,8887 |
| 14 | Буа | 125,9 | 1,0706 | 138,7 | 0,9826 | 6,1 | 0,7443 | 5,6 | 0,9982 | 3,7956 | 0,9489 |
| 15 | Югары Ослан | 129,6 | 1,0400 | 138,0 | 0,9875 | 2,9 | 1,5655 | 5,5 | 1,0164 | 4,6095 | 1,1524 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 16 | Биектау | 147,2 | 0,9157 | 134,2 | 1,0155 | 2,6 | 1,7462 | 5,7 | 0,9807 | 4,6580 | 1,1645 |
| 17 | Чүпрәле | 118,6 | 1,1365 | 159,1 | 0,8566 | 8,1 | 0,5605 | 5,5 | 1,0164 | 3,5699 | 0,8925 |
| 18 | Алабуга | 145,8 | 0,9245 | 131,4 | 1,0371 | 2,4 | 1,8917 | 5,4 | 1,0352 | 4,8885 | 1,2221 |
| 19 | Зәй | 160,0 | 0,8424 | 141,0 | 0,9665 | 4,7 | 0,9660 | 5,6 | 0,9982 | 3,7731 | 0,9433 |
| 20 | Яшел Үзән | 194,1 | 0,6944 | 144,8 | 0,9412 | 2,7 | 1,6815 | 5,7 | 0,9807 | 4,2978 | 1,0744 |
| 21 | Кайбыч | 128,5 | 1,0489 | 152,7 | 0,8925 | 4,2 | 1,0810 | 5,6 | 0,9982 | 4,0206 | 1,0051 |
| 22 | Кама Тамагы | 149,7 | 0,9004 | 169,2 | 0,8054 | 3,4 | 1,3353 | 5,7 | 0,9807 | 4,0218 | 1,0055 |
| 23 | Кукмара | 149,6 | 0,9010 | 144,6 | 0,9425 | 2,6 | 1,7462 | 5,6 | 0,9982 | 4,5878 | 1,1470 |
| 24 | Лаеш | 177,6 | 0,7590 | 123,5 | 1,1035 | 2,8 | 1,6214 | 5,6 | 0,9982 | 4,4821 | 1,1205 |
| 25 | Лениногорск | 105,9 | 1,2728 | 134,3 | 1,0147 | 6,8 | 0,6676 | 5,9 | 0,9475 | 3,9027 | 0,9757 |
| 26 | Мамадыш | 141,2 | 0,9546 | 142,2 | 0,9584 | 2,0 | 2,2700 | 5,5 | 1,0164 | 5,1993 | 1,2998 |
| 27 | Менделеев | 136,2 | 0,9896 | 138,3 | 0,9854 | 3,0 | 1,5133 | 5,6 | 0,9982 | 4,4866 | 1,1216 |
| 28 | Минзәлә | 143,4 | 0,9400 | 147,6 | 0,9233 | 5,5 | 0,8255 | 5,6 | 0,9982 | 3,6869 | 0,9217 |
| 29 | Мөслим | 126,0 | 1,0698 | 129,8 | 1,0499 | 5,4 | 0,8407 | 5,7 | 0,9807 | 3,9411 | 0,9853 |
| 30 | Түбән Кама | 134,9 | 0,9992 | 131,0 | 1,0403 | 4,3 | 1,0558 | 5,5 | 1,0164 | 4,1117 | 1,0279 |
| 31 | Яңа Чишмә | 116,0 | 1,1620 | 129,0 | 1,0564 | 6,4 | 0,7094 | 5,6 | 0,9982 | 3,9260 | 0,9815 |
| 32 | Нурлат | 147,6 | 0,9132 | 131,4 | 1,0371 | 5,9 | 0,7695 | 5,5 | 1,0164 | 3,7362 | 0,9341 |
| 33 | Питрәч | 152,6 | 0,8833 | 137,3 | 0,9926 | 2,7 | 1,6815 | 5,7 | 0,9807 | 4,5380 | 1,1345 |
| 34 | Балык Бистәсе | 139,9 | 0,9635 | 138,5 | 0,9840 | 2,6 | 1,7462 | 5,4 | 1,0352 | 4,7288 | 1,1822 |
| 35 | Саба | 124,8 | 1,0800 | 123,4 | 1,1044 | 2,4 | 1,8917 | 5,1 | 1,0961 | 5,1722 | 1,2930 |
| 36 | Сарман | 145,0 | 0,9296 | 147,0 | 0,9271 | 5,7 | 0,7965 | 5,7 | 0,9807 | 3,6339 | 0,9085 |
| 37 | Спас | 125,1 | 1,0775 | 105,6 | 1,2905 | 4,8 | 0,9458 | 5,7 | 0,9807 | 4,2945 | 1,0736 |
| 38 | Тәтеш | 136,3 | 0,9889 | 181,2 | 0,7521 | 4,8 | 0,9458 | 5,6 | 0,9982 | 3,6851 | 0,9213 |
| 39 | Гукай | 145,2 | 0,9283 | 128,7 | 1,0589 | 5,1 | 0,8902 | 5,6 | 0,9982 | 3,8756 | 0,9689 |
| 40 | Теләче | 139,0 | 0,9697 | 148,1 | 0,9202 | 2,6 | 1,7462 | 5,5 | 1,0164 | 4,6524 | 1,1631 |
| 41 | Чирмешән | 113,2 | 1,1907 | 130,6 | 1,0435 | 6,5 | 0,6985 | 5,7 | 0,9807 | 3,9134 | 0,9783 |
| 42 | Чистай | 110,0 | 1,2254 | 126,0 | 1,0816 | 6,3 | 0,7206 | 5,5 | 1,0164 | 4,0439 | 1,0110 |
| 43 | Ютазы | 111,4 | 1,2100 | 129,3 | 1,0540 | 6,9 | 0,6580 | 5,9 | 0,9475 | 3,8694 | 0,9673 |
| | ТР буенча барлыгы | 134,79 | 1,0000 | 136,28 | 1,0000 | 4,54 | 1,0000 | 5,59 | 1,0000 | 4,0000 | 1,0000 |

2016 елда үсемлекчелек өлкәсендә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә бәйле булмаган ярдәм күрсәтүгә федераль бюджеттан средстволар хисабына субсидияләр бирү тәртибенә № 2 кушымта

**ТР буенча авыл хуҗалыгы культураларының ашлык берәмлекләренә күчерү коэффициентлары**

| Авыл хуҗалыгы культуралары | Күчерү коэффициентлары |
|---|---|
| Бөртекле | 1,0 |
| Бөртекле-кузаклы | 1,2 |
| Бөртеккә кукуруз | 1,3 |
| Шикәр чөгендере | 0,16 |
| Бәрәңге | 0,2 |
| Яшелчә | 0,2 |
| Җимеш-җиләк культуралары | 1,2 |
| Май культуралары (рапс, рыжик, соя һ.б.) | 1,5 |
| көнбагыш | 1,5 |
| Күпьеллык үләннәр | |
| орлыкка | 10,0 |
| печәнгә | 0,50 |
| Яшел азыкка, сенажга, силоска (яшел массаның авырлыгы) | 0,18 |
| Терлек азыгына кукуруз (яшел массаның авырлыгы) | |
| яшел азыкка | 0,17 |
| силоска | 0,26 |
| Бер еллык үләннәр | |
| печәнгә | 0,40 |
| яшел азыккана, сенажга (яшел массаның авырлыгы) | 0,18 |
| Силоска терлек азыгы культуралары (яшел массаның авырлыгы) | 0,17 |
| Тамыразык | 0,16 |
| Лён-долгунец | |
| орлыкка | 1,65 |
| җепселгә | 3,85 |
| саламга | 0,41 |

ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 15.01.2016 ел, № 1/2-пр боерыгына № 2 кушымта

**2016 елда сатып алынган элита орлыклары буенча авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре чыгымнарының бер өлешен каплауга федераль бюджеттан субсидияләр бирү тәртибе**

1. Бу Тәртип Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан расланып, Дәүләт селекция казанышлары реестрына кертелгән, файдалануга рөхсәт ителгән, сатып алынган элита сортлары орлыклары буенча авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш) чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр (алга таба – субсидияләр, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре) бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр алуга авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләрен сайлап алуның критерие булып үсемлекчелек продукциясен җитештерү һәм сату тора.

3. Субсидияләр бирү шарты булып 2016 елда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең милкендә, аренда шартларында авыл хуҗалыгы культураларының чәчүлек мәйданнарына ия булуы тора.

4. Арбитраж суд тарафыннан субсидияләр алучыларга карата бөлгенлеккә төшү турында эш кузгатылганда, алар (алучылар) бу хакта, эш кузгатылган көнне, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) язмача хәбәр итәргә тиеш.

Субсидияләр үзләренә карата арбитраж суды тарафыннан бөлгенлеккә төшү тарафыннан эш кузгатылган авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә бирелми.

5. Субсидияләр бирүнең максатлары булып үсемлекчелек продукциясе уңышын һәм җитештерүне арттыру тора.

6. Авыл хуҗалыгы культуралары исемлеге һәм сатып алынган элита орлыклары өчен субсидияләр ставкалары Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы боерыгы тарафыннан раслана.

7. Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре сатып алынган элита орлыклары өчен чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидия алу өчен Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының муниципаль районнарындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренә (алга таба Идарә) түбәндәге документларны тапшыра:

а) түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр алуга гариза;

б) авыл хуҗалыгы культуралары орлыкларын җибәрүгә килешү;

в) түләүче-банк тарафыннан расланган түләү поручениесе;

г) товар-транспорт накладное;

д) счет-фактуралар;

е) туры килү сертификаты;

е) карантин сертификаты һәм фито-санитария контрольлеге акты (орлыкларны Татарстан Республикасына читтән керткәндә);

ж) милектә, арендада яки башкача законлы нигездә авыл хуҗалыгы культураларының чәчүлек мәйданнарына ия булуны раслаучы документлар;

з) Министрлык тарафыннан расланган форма буенча, тиешле субсидияләр турында белешмә-исәпләмә.

Тапшырылган документларның күчермәләре авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан раслана.

8. Идарәләр:

а) субсидияләр алуга гаризаларны, алынган көнне, журналда терки, журнал битләренә номер сугылган һәм тегелгән, мөһер белән расланган, беркетелгән булырга тиеш;

б) бу Тәртипнең 6 пункты нигезендә тапшырылган документларны карап тикшерә. Документларны карап тикшерү срогы – гариза теркәтүгә алынганнан соң 15 эш көне;

в) әлеге документлар нигезендә, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан тапшырылган тиешле субсидияләр турында белешмә-исәпләмәләрне раслый һәм Министрлыкка тапшыра.

Субсидия бирүдән баш тартуга нигезләр булып тора:

документларны тулысынча тапшырмау;

документларда тулы булмаган, ялган мәгълүматларның булуы;

бюджет йөкләмәләре лимитының булмавы.

9. Министрлык бюджет средстволарын баш бүлүче булып тора һәм Федераль казначылык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган үзенең лицевой счетыннан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең расчет счетларына, акча средстволарын бирү турында карар кабул ителгәннән соң 10 эш көне эчендә, акча средстволарын күчерүне хәл итә.

Министрлык, Министрлык тарафыннан расланылган форма буенча, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре белән субсидия бирү турында килешү (алга таба – Килешү) төзи, анда субсидияләр бирүнең мәҗбүри шарты булып алучыларның Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контрольлеге органнары тарафыннан субсидияләр алучыларның субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерүгә ризалык бирүе тора.

Субсидияләр күчерүгә нигез булып Идарәләр тарафыннан Министрлыкка тапшырылган тиешле субсидияләр турында белешмә-исәпләмәләр тора.

10. Бирелгән субсидияләр, бу Тәртиптә билгеләнгән аларны бирү максатларын һәм шартларын бозу, субсидияләрне максатчан файдаланмау яки субсидияләр алу өчен ялган мәгълүматлар һәм документлар тапшыру очраклары ачыкланганда, Министрлык таләбе алынганнан соң 60 көн эчендә федераль бюджет керемөнә кире кайтарылырга тиеш.

11. Субсидияләр алу турында килешүләрдә күздә тотылган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр калдыклары субсидияләр алучылар тарафыннан, субсидияләр бирелгән елдан соң килгән елның 1 декабренә кадәр, федераль бюджет керемөнә кире кайтарылырга тиеш.

12. Бу Тәртипнең 10 һәм 11 пунктларында күрсәтелгән бюджет средстволарын федераль бюджет кеременә ихтыярый рәвештә кире кайтарудан баш тарту очрагында, алар, закон нигезендә, мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.

13. Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контрольлеге органнары авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

14. Идарәләр тарафыннан Министрлыкка тапшырыла торган һәм авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан Идарәгә тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык аларның җитәкчеләренә һәм баш бухгалтерларына йөкләнә. Закон бозучыларга карата закон нигезендә күздә тотылган җаваплылык чаралары кулланыла.

15. Бюджет средстволарыннан максатчан файдалануга Министрлык контрольлек итә.

ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 15.01.2016 ел, № 1/2-пр боерыгына № 3 кушымта

**2016 елда күп еллык җимеш һәм җиләк куакларын, интенсив типтагы бакчаларны утырту һәм карау буенча авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре чыгымнарының бер өлешен каплауга федераль бюджеттан субсидияләр бирү тәртибе**

1. Бу Тәртип күп еллык җимеш һәм җиләк куакларын, интенсив типтагы бакчаларны, утырту һәм карауны (гектарына кимендә 800 агач), аларның җимеш бирү чорына кадәр, җимеш һәм җиләк куаклары питомникларын карауны хәл итүче авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре чыгымнарының бер өлешен каплауга федераль бюджеттан средстволар хисабына субсидияләр (субсидияләр, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре, күп еллык җимеш һәм җиләк куаклары) бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр алуга авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләрен сайлап алу критерийләре булып тора:

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең Татарстан Республикасы территориясендә күп еллык җимеш һәм җиләк агач-куаклары мәйданнарына ия булуы;

бакча булдыру проектына ия булу;

елына кимендә бер гектар мәйданда күп еллык җимеш һәм җиләк агач-куакларын утыртуны хәл итү яки агымдагы финанс елы башына кимендә бер гектар мәйданда күп еллык җимеш һәм җиләк агач-куаларына ия булу.

3. Субсидияләр бирүнең шарты булып елына кимендә бер гектар мәйданда күп еллык җимеш һәм җиләк агач-куакларын утыртуны хәл итү яки агымдагы финанс елы башына кимендә бер гектар мәйданда күп еллык җимеш һәм җиләк агач-куакларына ия булу тора.

4. Арбитраж суд тарафыннан субсидияләр алучыларга карата бөлгенлеккә төшү турында эш кузгатылганда, алар (алучылар) бу хакта, эш кузгатылган көнне, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) язмача хәбәр итәргә тиеш.

Субсидияләр үзләренә карата арбитраж суды тарафыннан бөлгенлеккә төшү тарафыннан эш кузгатылган авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә бирелми.

5. Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү максатлары булып тора:

күп еллык җимеш һәм җиләк агач-куак мәйданнарын үстерү;

җимеш-җиләк культуралары продукциясен җитештерүне арттыру.

6. Күп еллык җимеш һәм җиләк агач-куакларын утырту  һәм карауга субсидияләр ставкалары Россия Федерациясе авыл хуҗалыгы министрлыгы боерыгы белән раслана.

7. Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре субсидияләр алу өчен Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының муниципаль районнарындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренә (алга таба  – Идарә) түбәндәге документларны тапшыра:

түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр алуга гариза;

бакча утырту проекты;

күп еллык җимеш һәм яшелчә агач-куакларын утырту һәм карау буенча эшләр башкаруга подряд килешүе һәм килешү буенча эшләргә түләү фактын раслаган документлар (подряд оешмасын җәлеп итү очрагында);

Россия Федерациясе Статистика дәүләт комитетының 11 ноябрь, 1999 ел, № 100 карары белән расланган "Башкарылган эшләрне кабул итү турында акт" № КС-2 формасы буенча, күп еллык жимеш һәм жиләк агач-куакларын утырту һәм карау буенча башкарылган эшләр акты;

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 16 май, 2003 ел, № 750 боерыгы белән расланган № 404-АПК формасы буенча, күп еллык үсентеләрне кабул итү акты;

Россия Федерациясе Статистика дәүләт комитетының 11 ноябрь, 1999 ел, № 100 карары белән расланган "Башкарылган эшләр һәм чыгымнар бәясе турында белешмә" № КС-3 формасы буенча күп еллык җимеш һәм җиләк агач-куакларын утырту һәм карау буенча башкарылган эшләр һәм чыгымнар бәясе турында белешмә;

милектә, арендада яки башкача законлы нигездә күп еллык җимеш һәм җиләк агач-куаклары мәйданнарына ия булуны раслаган документлар;

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча, тиешле субсидияләр турында белешмә-исәпләмә.

Тапшырылган документларның күчермәләре авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан раслана.

8. Идарәләр:

а) субсидияләр алуга гаризаларны, алынган көнне, журналда терки, журнал битләренә номер сугылган һәм тегелгән, мөһер белән расланган, беркетелгән булырга тиеш;

б) бу Тәртипнең 6 пункты нигезендә тапшырылган документларны карап тикшерә. Документларны карап тикшерү срогы – гариза теркәтүгә алынганнан соң 15 эш көне;

в) әлеге документлар нигезендә, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан тапшырылган тиешле субсидияләр турында белешмә-исәпләмәләрне раслый һәм Министрлыкка тапшыра.

Субсидия бирүдән баш тартуга нигезләр булып тора:

документларны тулысынча тапшырмау;

документларда тулы булмаган, ялган мәгълүматларның булуы;

бюджет йөкләмәләре лимитының булмавы.

9. Министрлык бюджет средстволарын баш бүлүче булып тора һәм Федераль казначылык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган үзенең лицевой счетыннан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең расчет счетларына,  акча средстволарын бирү турында карар кабул ителгәннән соң 10 эш көне эчендә, акча средстволарын күчерүне хәл итә.

Министрлык, Министрлык тарафыннан расланылган форма буенча, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре белән субсидия бирү турында килешү (алга таба – Килешү) төзи, анда субсидияләр бирүнең мәҗбүри шарты булып алучыларның Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контрольлеге

органнары тарафыннан субсидияләр алучыларның субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерүгә ризалык бирүе тора.

Субсидияләр күчерүгә нигез булып Идарәләр тарафыннан Министрлыкка тапшырылган тиешле субсидияләр турында белешмә-исәпләмәләр тора.

10. Бирелгән субсидияләр, бу Тәртиптә билгеләнгән аларны бирү максатларын һәм шартларын бозу, субсидияләрне максатчан файдаланмау яки субсидияләр алу өчен ялган мәгълүматлар һәм документлар тапшыру очраклары ачыкланганда, Министрлык таләбе алынганнан соң 60 көн эчендә федераль бюджет керемнә кире кайтарылырга тиеш.

11. Субсидияләр алу турында килешүләрдә күздә тотылган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр калдыклары субсидияләр алучылар тарафыннан, субсидияләр бирелгән елдан соң килгән елның 1 декабренә кадәр, федераль бюджет керемнә кире кайтарылырга тиеш.

12. Бу Тәртипнең 10 һәм 11 пунктларында күрсәтелгән бюджет средстволарын федераль бюджет керемнә ихтыярый рәвештә кире кайтарудан баш тарту очрагында, алар, закон нигезендә, мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.

13. Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контрольлеге органнары авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

14. Идарәләр тарафыннан Министрлыкка тапшырыла торган һәм авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан Идарәгә тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык аларның җитәкчеләренә һәм баш бухгалтерларына йөкләнә. Закон бозучыларга карата закон нигезендә күздә тотылган җаваплылык чаралары кулланыла.

15. Бюджет средстволарыннан максатчан файдалануга Министрлык контрольлек итә.

ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 15.01.2016 ел, № 1/2-пр боерыгына № 4 кушымта

**2016 елда файдаланудан төшеп калган иске бакчаларны агач-куаклардан чистартуга һәм чистартылган мәйданнарны рекультивацияләүгә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре чыгымнарының бер өлешен каплауга федераль бюджеттан субсидияләр бирү тәртибе**

1. Бу Тәртип авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш) файдаланудан төшеп калган иске

бакчаларны агач-куаклардан чистартуга һәм чистартылган мәйданнарны рекультивацияләүгә чыгымнарының бер өлешен каплауга федераль бюджеттан средстволар хисабына субсидияләр (алга таба – субсидияләр, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре) бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр алуга авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләрен сайлап алу критерийләре булып тора:

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең Татарстан республикасы территориясендә файдаланудан төшеп калган иске бакча мәйданнарына ия булуы;

чистартылган мәйданнарда яңа бакча утырту проектына ия булу.

3. Субсидияләр бирүнең шарты булып файдаланудан төшеп калган иске бакчаларны агач куаклардан чистартуны хәл итү һәм чистартылган мәйданнарның рекультивацияләү тора.

4. Арбитраж суд тарафыннан субсидияләр алучыларга карата бөлгенлеккә төшү турында эш кузгатылганда, алар (алучылар) бу хакта, эш кузгатылган көнне, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) язмача хәбәр итәргә тиеш.

Субсидияләр үзләренә карата арбитраж суды тарафыннан бөлгенлеккә төшү тарафыннан эш кузгатылган авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә бирелми.

5. Субсидияләр бирүнең максатлары булып бакчаларны яңарту, аларның мәйданнарын саклап калу һәм үстерү, җимеш-җиләк культураларының уңышын һәм җитештерү күләмнәрен арттыру тора.

6. Утыртылган елдан соң 30 елдан артыграк вакыт дәвамында файдаланылган бакчаларны агач-куаклардан чистартуга һәм чистартылган мәйданнарны рекультивацияләүгә субсидияләр ставкалары Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы боерыгы белән раслана.

7. Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре субсидияләр алу өчен Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының муниципаль районнарындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренә (алга таба – Идарә) түбәндәге документларны тапшыра:

түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр алуга гариза;

чистартылган мәйданда яңа бакча утырту проекты;

агач-куаклардан чистарту һәм рекультивацияләү эшләрен башкаруга подряд килешүе һәм килешү буенча эшләрне түләү фактын раслаган докукментлар (подряд оешмасын җәлеп итү очрагында);

хуҗалыкларның еллык хисаплары (иске бакчаларның яше һәм мәйданнары турында мәгълүматлардан торган);

Россия Федерациясе Статистика дәүләт комитетының 11 ноябрь, 1999 ел, № 100 карары белән расланган “Башкарылган эшләрне кабул итү турында акт” № КС-2 формасы буенча, бакчаны агач-куаклардан чистарту һәм чистартылган мәйданнарны рекультивацияләү буенча башкарылган эшләр акты;

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 16 май, 2003 ел, № 750 боерыгы белән расланган № 405-АПК формасы буенча, күп еллык үсентеләрне гамәлдән алу акты;

милектә, арендада яки башкача законлы нигездә файдаланудан төшеп калган иске бакча мәйданнарына ия булуны раслаган документлар;

Россия Федерациясе Статистика дәүләт комитетының 11 ноябрь, 1999 ел, № 100 карары белән расланган "Башкарылган эшләр һәм чыгымнар бәясе турында белешмә" № КС-3 формасы буенча бакчаны агач-куаклардан чистарту һәм чистартылган мәйданнарны рекультивацияләү буенча башкарылган эшләр һәм чыгымнар бәясе турында белешмә;

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча, тиешле субсидияләр турында белешмә-исәпләмә.

Тапшырылган документларның күчермәләре авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан раслана.

8. Идарәләр:

а) субсидияләр алуга гаризаларны, алынган көнне, журналда терки, журнал битләренә номер сугылган һәм тегелгән, мөһер белән расланган, беркетелгән булырга тиеш;

б) бу Тәртипнең 6 пункты нигезендә тапшырылган документларны карап тикшерә. Документларны карап тикшерү срогы – гариза теркәтүгә алынганнан соң 15 эш көне;

в) әлеге документлар нигезендә, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан тапшырылган тиешле субсидияләр турында белешмә-исәпләмәләрне раслый һәм Министрлыкка тапшыра.

Субсидия бирүдән баш тартуга нигезләр булып тора:

документларны тулысынча тапшырмау;

документларда тулы булмаган, ялган мәгълүматларның булуы;

бюджет йөкләмәләре лимитының булмавы.

9. Министрлык бюджет средстволарын баш бүлүче булып тора һәм Федераль казначылык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган үзенең лицевой счетыннан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең расчет счетларына, акча средстволарын бирү турында карар кабул ителгәннән соң 10 эш көне эчендә, акча средстволарын күчерүне хәл итә.

Министрлык, Министрлык тарафыннан расланылган форма буенча, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре белән субсидия бирү турында килешү (алга таба – Килешү) төзи, анда субсидияләр бирүнең мәҗбүри шарты булып алучыларның Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контрольлеге органнары тарафыннан субсидияләр алучыларның субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерүгә ризалык бирүе тора.

Субсидияләр күчерүгә нигез булып Идарәләр тарафыннан Министрлыкка тапшырылган тиешле субсидияләр турында белешмә-исәпләмәләр тора.

10. Бирелгән субсидияләр, бу Тәртиптә билгеләнгән аларны бирү максатларын һәм шартларын бозу, субсидияләрне максатчан файдаланмау яки субсидияләр алу өчен ялган мәгълүматлар һәм документлар тапшыру

очраклары ачыкланганда, Министрлык таләбе алынганнан соң 60 көн эчендә федераль бюджет керемено кире кайтарылырга тиеш.

11. Субсидияләр алу турында килешүләрдә күздә тотылган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр калдыклары субсидияләр алучылар тарафыннан, субсидияләр бирелгән елдан соң килгән елның 1 декабренә кадәр, федераль бюджет керемено кире кайтарылырга тиеш.

12. Бу Тәртипнең 10 һәм 11 пунктларында күрсәтелгән бюджет средстволарын федераль бюджет керемено ихтыярый рәвештә кире кайтарудан баш тарту очрагында, алар, закон нигезендә, мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.

13. Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контрольлеге органнары авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

14. Идарәләр тарафыннан Министрлыкка тапшырыла торган һәм авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан Идарәгә тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык аларның җитәкчеләренә һәм баш бухгалтерларына йөкләнә. Закон бозучыларга карата закон нигезендә күздә тотылган җаваплылык чаралары кулланыла.

15. Бюджет средстволарыннан максатчан файдалануга Министрлык контрольлек итә.

ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 15.01.2016 ел, № 1/2-пр боерыгына № 5 кушымта

**2016 елда үзләре җитештереп саткан һәм (яки) үзләре эшкәртүгә төяп озаткан сөтнең бер килограммына авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре чыгымнарының бер өлешен каплауга федераль бюджеттан субсидияләр бирү тәртибе**

1. Бу Тәртип югары һәм (яки) беренче сортлы үзләре җитештереп саткан һәм (яки) үзләре эшкәрткән сыер сөтенең һәм (яки) кәҗә сөтенең бер килограммына авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш) (алга таба – авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре) чыгымнарының бер өлешен каплауга федераль бюджеттан субсидияләр (алга таба – сөт, субсидияләр) бирү тәртибен билгели.

2. Субсидияләр алуга авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләрен сайлап алуның критерие булып аларның Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының (алга таба – Министрлык) Татарстан Республикасы муниципаль районнарындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренә (алга таба – Идарәләр) мөрәҗәгать иткән айның беренче числосына сыерларның һәм (яки) кәҗәләрнең баш санына ия булып, үзләре җитештергән сөтне сату һәм (яки) үзләре эшкәртүгә төяп озатуны хәл итүе тора.

3. Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү шартлары булып тора: югары һәм (яки) беренче сортлы сыер сөтен һәм (яки) кәҗә сөтен җитештерү, сату һәм (яки) үзләре эшкәртүгә төяп озату.

4. Арбитраж суд тарафыннан субсидияләр алучыларга карата бөлгенлеккә төшү турында эш кузгатылганда, алар (алучылар) бу хакта, эш кузгатылган көнне, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) язмача хәбәр итәргә тиеш.

Субсидияләр үзләренә карата арбитраж суды тарафыннан бөлгенлеккә төшү тарафыннан эш кузгатылган авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә бирелми.

5. Субсидияләр бирүнең максаты булып авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә сөт җитештерүгә ярдәм итү тора.

Субсидия күләме түбәндәге формула буенча исәпләнелә,

$$W_i = Whi + W,$$

биредә:

Whi – авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә бирелә торган югары һәм (яки) беренче сортлы сыер сөтенә карата субсидия күләме;

W – авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә бирелә торган кәҗә сөтенә карата субсидия күләме.

7. Агымдагы финанс елына авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә ($W_Hi$), бирелә торган югары һәм (яки) беренче сортлы сыер сөтенә карата субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнелә:

$$W_Hi = S_H x VHi,$$

биредә:

$S_H$ – хисап чорында югары һәм (яки) беренче сортлы сыер сөтен сату һәм (яки) үзенең эшкәртүенә төяп җибәрү күләмнәреннән чыгып, Министрлык тарафыннан расланыла торган югары һәм (яки) беренче сортлы сыер сөтенә карата сатылган һәм (яки) үзенең эшкәртүенә төяп озатылган сөтнең 1 килограммына ставка;

$V_{Hi}$ – авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан югары һәм (яки) беренче сортлы сатылган һәм (яки) үзенең эшкәртүенә төяп озатылган сыер сөте күләме.

8. Агымдагы финанс елында авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (W), бирелә торган кәҗә сөтенә карата субсидия күләме түбәндәге формула буенча исәпләнелә:

$$W = S x V$$

биредә:

S – хисап чорында сатылган һәм (яки) үзенең эшкәртүе өчен төяп җибәрелгән кәҗә сөте күләмнәреннән чыгып, Министрлык тарафыннан расланылган кәҗә сөтенә карата сатылган һәм (яки) үзенең эшкәртү өчен төяп җибәрелгән сөтнең 1 килограммы өчен ставка;

V – авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан сатылган һәм (яки) үзенең җитештерүе өчен төяп озатылган кәҗә сөте күләме.

9. Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре субсидияләр алу өчен түбәндәге документларны тапшыра:

а) түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, сатылган һәм (яки) үзенең эшкәртүе өчен төяп озатылган сөтнең 1 килограммына субсидия бирү турында гариза;

б) авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесенең сыер сөте яки кәҗә сөтен сату һәм (яки) үзенең эшкәртүе өчен төяп озату фактын раслаган документлар реестры, Министрлык билгеләгән раслаган форма буенча авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе раслаган товар накладнойлары күчермәләре белән бергә.

Сөтне үзләре эшкәртү производствосына ия булган авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре хуҗалык эчендәге билгеләнештәге товар накладное (сөт ташуга) күчермәсе (расланган), үзенең эшкәртүе өчен төяп озатылган товарлыклы сөтнең пландагы үзкыйммәтен күрсәтеп, бухгалтериядән белешмә һәм сөт продукциясенә туры килү сертификатын тапшыра;

в) 1 килограмм сөткә чыгымнарның бер өлешен каплауга средстволар алу өчен вәкаләтле органга мөрәҗәгать иткән айның беренче числосына сыерлар һәм (яки) кәҗәләрнең баш санына ия булу;

г) бухгалтерия хисабы нигезендә, Министрлык тарафыннан расланган форма буенча, хисап чорында авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе җитештергән сөт күләме, сатылган һәм (яки) үзенең эшкәртүе өчен төяп озатылган сөт күләме һәм сыйфаты турында мәгълүматлар;

д) бу пунктның “б” пунктчасында күрсәтелгән документлар нигезендә Министрлык тарафыннан раслаган форма буенча, сатылган һәм (яки) үзләре эшкәртүгә төяп озатылган сыер сөтенең яки кәҗә сөтенең 1 килограммына чыгымнарның бер өлешен каплауга федераль бюджеттан субсидияләр бирү турында белешмә-исәпләмә.

Тапшырылган документларның күчермәләре авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан раслана.

10. Идарәләр:

а) субсидияләр алуга гаризаларны, алынган көнне, журналда терки, журнал битләренә номер сугылган һәм тегелгән, мөһер белән расланган, беркетелгән булырга тиеш;

б) бу Тәртипнең 9 пункты нигезендә тапшырылган документларны карап тикшерә. Документларны карап тикшерү срогы – гариза теркәтүгә алынганнан соң 15 эш көне;

в) бу Тәртипнең 9 пунктында күрсәтелгән документлар нигезендә, Министрлык тарафыннан расланган формалар буенча Татарстан Республикасы муниципаль районы буенча сыер сөтен яки кәҗә сөтен сату һәм (яки) үзенең эшкәртүенә озату буенча (сөтнең физик күләмен күрсәтеп) җыелма реестрлар;

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча, Татарстан Республикасы муниципаль районы буенча сатылган һәм (яки) үзләре эшкәртүгә төяп озатылган сыер сөтенең яки кәҗә сөтенең 1 килограммына авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре чыгымнарының бер өлешен каплауга федераль бюджеттан субсидияләр бирү өчен җыелма белешмә-исәпләмәләр;

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча, хисап чорында җитештерелгән сөт күләмнәре, сатылган һәм (яки) үзләре эшкәртүгә төяп озатылган сөт күләмнәре һәм сыйфаты турында мәгълүматлар;

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча, 2015 ел өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан сатылган һәм (яки) үзенең эшкәртүе өчен төяп озатылган терлекчелек продукциясенең сыйфаты турында мәгълүматлар;

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча сөт җитештерү һәм сату турында мәгълүматлар.

Субсидия бирүдән баш тартуга нигезләр булып тора:

документларны тулысынча тапшырмау;

документларда тулы булмаган, ялган мәгълүматларның булуы;

бюджет йөкләмәләре лимитының булмавы.

11. Министрлыкның Азык-төлек базарын үстерү бүлеге идарәләренең җыелма реестры нигезендә, Министрлык тарафыннан расланган форма буенча, ай саен Татарстан Республикасы буенча җыелма реестр булдырып, хисап аеннан соң килүче айның 10нчы числосына кадәр Министрлыкның терлекчелек тармакларын үстерү бүлегенә тапшыра.

12. Министрлык бюджет средстволарын баш бүлүче булып тора һәм Федераль казначылык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган үзенең лицевой счетыннан Идарәләрнең Федераль казначылык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе территориаль бүлекләрендә ачылган лицевой счетларына, акча средстволарын бирү турында карар кабул ителгәннән соң 2 эш көне эчендә, акча средстволарын күчерүне хәл итә.

Субсидияләр күчерүгә нигез булып Идарәләр тарафыннан Министрлыкка, Министрлык тарафыннан расланган форма буенча, Татарстан Республикасы муниципаль районы буенча тиешле субсидияләр турында

җыелма белешмә-исәпләмәләр тора. Идарәләр 5 эш көне эчендә субсидияләрне авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең расчет счетларына күчерә.

Министрлык, Министрлык тарафыннан расланылган форма буенча, субсидия бирү турында килешү (алга таба – Килешү) төзи, анда субсидияләр бирүнең мәҗбүри шарты булып алучыларның Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контрольлеге органнары тарафыннан субсидияләр алучыларның субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерүгә ризалык бирүе тора.

13. Бирелгән субсидияләр, бу Тәртиптә билгеләнгән аларны бирү максатларын һәм шартларын бозу, субсидияләрне максатчан файдаланмау яки субсидияләр алу өчен ялган мәгълүматлар һәм документлар тапшыру очраклары ачыкланганда, Министрлык таләбе алынганнан соң 60 көн эчендә федераль бюджет кеременә кире кайтарылырга тиеш.

14. Субсидияләр алу турында килешүләрдә күздә тотылган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр калдыклары субсидияләр алучылар тарафыннан, субсидияләр бирелгән елдан соң килгән елның 1 декабренә кадәр, федераль бюджет керемен кире кайтарылырга тиеш.

15. Бу Тәртипнең 13 һәм 14 пунктларында күрсәтелгән бюджет средстволарын федераль бюджет керемен ихтыярый рәвештә кире кайтарудан баш тарту очрагында, алар, закон нигезендә, мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.

16. Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контрольлеге органнары авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

17. Идарәләр тарафыннан Министрлыкка тапшырыла торган һәм авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан Идарәгә тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык аларның җитәкчеләренә һәм баш бухгалтерларына йөкләнә. Закон бозучыларга карата закон нигезендә күздә тотылган җаваплылык чаралары кулланыла.

18. Бюджет средстволарыннан максатчан файдалануга Министрлык контрольлек итә.

ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 15.01.2016 ел, № 1–2-пр боерыгына № 6 кушымта

**2016 елда сарыклар һәм ана кәҗәләрнең баш санын артыру буенча авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре чыгымнарының бер өлешен каплауга федераль бюджеттан субсидияләр бирү тәртибе**

1.Бу Тәртип авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш) (алга таба – авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре) сарыкларның һәм ана кәҗәләрнең баш санын арттыру буенча чыгымнарның бер өлешен каплауга федераль бюджет средстволары хисабына субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү механизмын билгели.

2.Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләрен субсидияләр алуга сайлап алуга критерий булып сарыклар һәм (яки) кәҗәләр үрчетү, үстерү тора.

3.Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә сарыкларның һәм кәҗәләрнең баш санын арттыру буенча чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирүнең шартлары булып тора:

2016 елда дәүләт нәселле терлекләр регистрында теркәүгә алыну турында таныклыкка ия булган, нәселле терлекләр заводларыннан һәм нәселле терлекләр репродукторларыннан, шулай ук импорт буенча нәселле сарыклар һәм (яки) кәҗәләр сатып алу;

сарыклар һәм кәҗәләрнең баш санына ия булу.

4. Арбитраж суд тарафыннан субсидияләр алучыларга карата бөлгенлеккә төшү турында эш кузгатылганда, алар (алучылар) бу хакта, эш кузгатылган көнне, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) язмача хәбәр итәргә тиеш.

Субсидияләр үзләренә карата арбитраж суды тарафыннан бөлгенлеккә төшү тарафыннан эш кузгатылган авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә бирелми.

5.Субсидияләр бирүнең шартлары булып терлекчелекнең аерым кече тармакларын әзерләү, шул исәптән сарыклар һәм кәҗәләрнең баш санын арттыруны тәэмин итү өчен икътисадый шартлар тудыру тора.

6.Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә сарыкларның һәм (яки) ана кәҗәләрнең баш санын арттыру буенча чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү түбәндәгеләр хисабыннан хәл ителә:

сарыклар (бер яшьлек һәм аннан зуррак саулык бәрәннәрне кертеп) – бер килограмм тере авырлык өчен 30,0 сум;

ана кәҗәләр (бер яшьлек һәм аннан зуррак яшь ана кәҗәләрне кертеп) – бер  килограмм тере авырлык өчен 200, 0 сум.

7.Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре субсидия алу өчен Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидия бирү турында гариза;

сатып алынган айда фермада терлек һәм кош-кортның хәрәкәте турында хуҗалык эче хисабы күчермәсе;

2016 елда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең нәселле сарыклар һәм (яки) ана кәҗәләр сатып алуын раслаган, түләүче – банк раслаган өземтә белән, түләү поручениесе, килешү күчермәсе, счет-фактуралар, накладной яки гурт ведомосте;

милектә, арендада яки башкача законлы нигездә авыл хуҗалыгы культураларының чәчүлек мәйданнарына ия булуын раслаган документлар.

Тапшырылган документларның күчермәләре авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан раслана.

Министрлык:

а) субсидияләр алуга гаризаларны, алынган көнне, журналда терки, журнал битләренә номер сугылган, тегелгән һәм мөһер белән расланган-беркетелгән булырга тиеш;

б) бу Тәртипнең 7 пункты нигезендә тапшырылган документларны карап тикшерә.

Документларны карап тикшерү срогы гариза теркәүгә алынганнан соң 15 эш көненнән артмаска тиеш.

Субсидия бирүдән баш тартуга нигезләр булып тора:

документларны тулысынча тапшырмау;

документларда тулы булмаган, ялган мәгълүматларның булуы;

бюджет йөкләмәләре лимитының булмавы.

9. Министрлык бюджет средстволарын баш бүлүче булып тора һәм Федераль казначылык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә

ачылган үзенең лицевой счетыннан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең расчет счетларына, акча средстволарын бирү турында карар кабул ителгәннән соң 10 эш көне эчендә, акча средстволарын күчерүне хәл итә.

Министрлык, Министрлык тарафыннан расланылган форма буенча, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре белән субсидия бирү турында килешү (алга таба – Килешү) төзи, анда субсидияләр бирүнең мәҗбүри шарты булып алучыларның Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контрольлеге органнары тарафыннан субсидияләр алучыларның субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерүгә ризалык бирүе тора.

10. Бирелгән субсидияләр, бу Тәртиптә билгеләнгән аларны бирү максатларын һәм шартларын бозу, субсидияләрне максатчан файдаланмау яки субсидияләр алу өчен ялган мәгълүматлар һәм документлар тапшыру очраклары ачыкланганда, Министрлык таләбе алынганнан соң 60 көн эчендә федераль бюджет кеременә кире кайтарылырга тиеш.

11. Субсидияләр алу турында килешүләрдә күздә тотылган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр калдыклары субсидияләр алучылар тарафыннан, субсидияләр бирелгән елдан соң килгән елның 1 декабренә кадәр, федераль бюджет кеременә кире кайтарылырга тиеш.

12. Бу Тәртипнең 10 һәм 11 пунктларында күрсәтелгән бюджет средстволарын федераль бюджет кеременә ихтыярый рәвештә кире кайтарудан баш тарту очрагында, алар, закон нигезендә, мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.

13. Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контрольлеге органнары авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

14. Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан Министрлыкка тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык аларның җитәкчеләренә һәм баш бухгалтерларына йөкләнә. Закон бозучыларга карата закон нигезендә күздә тотылган җаваплылык чаралары кулланыла.

15. Бюджет средстволарыннан максатчан файдалануга Министрлык контрольлек итә.

ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 15.01.2016 ел, № ½-пр боерыгына № 7 кушымта

**2016 елда нәселле терлекчелеккә ярдәм итүгә федераль бюджеттан субсидияләр бирү тәртибе**

1. Бу Тәртип авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш) нәселле терлекчелеккә, шул исәптән итчелек юнәлешендәге нәселле мөгезле эре терлек асрауга ярдәм итүгә федераль бюджет средстволары хисабына субсидияләр (алга таба – субсидияләр, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре) бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр алуга авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләрен сайлап алу критерийләре булып терлекчелек продукциясен җитештерү һәм сату тора.

3. Субсидияләр бирүнең шартлары булып тора:

Татарстан Республикасы территориясендә, нәселле терлекчелек оешмаларының дәүләт нәселле терлекләр регистрында теркәлгән нәселле терлекләргә ия булуы;

Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең Татарстан Республикасы территориясендә терлекләргә ия булуы.

3. Арбитраж суд тарафыннан субсидияләр алучыларга карата бөлгенлеккә төшү турында эш кузгатылганда, алар (алучылар) бу хакта, эш кузгатылган көнне, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) язмача хәбәр итәргә тиеш.

Субсидияләр үзләренә карата арбитраж суды тарафыннан бөлгенлеккә төшү тарафыннан эш кузгатылган авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә бирелми.

4. Субсидияләр бирүнең максаты булып нәселле терлекчелеккә ярдәм итү, шул исәптән нәселле һәм гадәти терлекләрне үстерүне, үрчетүне һәм терлекләрне ясалма орлыкландыру колачын киңәйтүне тәэмин итү тора.

5. Субсидияләр авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә түбәндәге юнәлешләр буенча нәселле терлекчелеккә ярдәм итү, шул исәптән итчелек юнәлешендәге нәселле мөгезле эре терлек асрауга ярдәм итү (алга таба – нәселле терлекчелеккә ярдәм итүгә субсидияләр) максатында бирелә:

а) нәселле терлекчелеккә ярдәм итү, шул исәптән:

нәселле ана терлекләрне асрау, итчелек юнәлешендәге нәселле мөгезле эре терлектән тыш;

нәсел сыйфаты буенча тикшерелгән яки әлеге сыйфатны бәяләү процессындагы, 16 айдан зуррак сөтчелек юнәлешендәге нәселле үгезләрне (алга таба – сөтчелек юнәлешендәге нәселле үгезләр) асрау;

терлекнең туган иле тарафыннан бирелгән геномын бәяләү нәтиҗәләре буенча сөт җитештерүчәнлекне һәм технологик сыйфатларны яхшыртучы сөтчелек юнәлешендәге нәселле үгезләр, шул исәптән импорт буенча, сатып алу;

сөтчелек юнәлешендәге нәселле яшь мөгезле  эре терлек сатып алу;

сөтчелек юнәлешендәге нәселле үгезләр орлыкларын сатып алу;

сөтчелек юнәлешендәге нәселле мөгезле эре терлек яралгыларын сатып алу, шул исәптән импорт буенча;

б) итчелек юнәлешендәге нәселле мөгезле эре терлек асрауга ярдәм итү, шул исәптән:

итчелек юнәлешендәге токымлы ана мөгезле эре терлекне асрау;

нәсел сыйфаты тикшерелгән яки әлеге сыйфатны бәяләү процессындагы, 16 айдан зуррак булган, итчелек юнәлешендәге токымлы үгезләр (алга таба – итчелек юнәлешендәге токымлы үгезләр);

терлекнең туган иле тарафыннан бирелгән геномын бәяләү нәтиҗәләре буенча ит җитештерүчәнлекне һәм технологик сыйфатларны яхшыртучы итчелек юнәлешендәге нәселле үгезләр, шул исәптән импорт буенча, сатып алу;

итчелек юнәлешендәге нәселле яшь мөгезле эре терлек сатып алу;

итчелек юнәлешендәге нәселле үгезләр орлыкларын сатып алу.

6. Нәселле терлекчелеккә ярдәм итүгә средстволар Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югарыгы башкарма органы вәкаләт биргән орган (алга таба – вәкаләтле орган) тарафыннан билгеләнелә торган ставкалар буенча түбәндәге максатларга, Россия Федерациясе субъектына күздә тотылган средстволар чикләрендә, бирелә:

а) Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан расланыла торган исемлеккә кертелгән авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең югарыгы башкарма органнары тәкъдиме белән, – 1 шартлы башка ставка буенча нәселле ана терлекләр асрауга (сөтчелек һәм итчелек буенча терлекчелектә – хисап финанс елында тере бер бозау тудырган бер сыер исәбеннән). Нәселле ана терлекләрнең баш санын шартлы башка күчерү өчен

коэффициентлар Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан билгеләнелә;

б) Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлеккә кертелгән терлекләрне ясалма орлыкландыру буенча оешмаларга, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең югарыгы башкарма органнары тәкъдиме белән, – бер башка ставка исәбеннән, нәселле үгезләр асрауга;

в) терлекләрне ясалма орлыкландыру буенча оешмаларга – дәүләт нәселле терлекләр регистрында теркәлгән нәселле үгезләр сатып алуга, шул исәптән импорт буенча, 1 кг тере авырлык ставкасы буенча;

г) авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләреннән – дәүләт нәселле терлекләр регистрында теркәлгән, сөтчелек һәм итчелек юнәлешләрендәге нәселле яшь мөгезле эре терлек сатып алуга, 1 кг тере авырлык ставкасы буенча;

д) терлекләрне ясалма орлыкландыру буенча оешмаларга – 1 доза өчен ставка буенча, нәселле үгезләр орлыкларын сатып алуга;

е) Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан расланган исемлеккә кертелгән терлекләрне ясалма орлыкландыру буенча оешмаларга – сөтчелек юнәелешендәге мөгезле эре терлек яралгыларын сатып алуга, шул исәптән импорт буенча, 1 данә исәбеннән ставка буенча.

7. Нәселле терлекчелеккә ярдәм итүгә, шул исәптән түбәндәгеләргә субсидия алу өчен:

7.1. Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре нәселле ана терлекләр асрауга сөтчелек юнәлешендәге нәселле үгезләр асрауга, итчелек юнәлешендәге токымлы ана мөгезле эре терлек асрауга, итчелек юнәлешендәге нәселле үгезләр асрауга субсидия алу өчен Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

а) Министрлык тарафыннан расланган форма буенча белешә-исәпләмә;

б) фермада кош-корт һәм терлекнең хәрәкәте турында хуҗалык эче хисабы күчермәсе;

в) 2015 елга рәсми статистика хисабы өчен нигез булып торган терлекчелекнең торышы турында мәгълүмат;

г) үзенең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү турында гариза.

7.2. Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре сөтчелек юнәлешендәге нәселле үгезләр, шул исәптән импорт буенча, сатып алуга, сөтчелек юнәлешендәге нәселле яшь мөгезле эре терлек сатып алуга, шул исәптән импорт буенча, сөтчелек юнәлешендәге нәселле үгезләр орлыкларын сатып алуга, шул исәптән импорт буенча, сөтчелек юнәлешендәге нәселле мөгезле эре терлек яралгыларын сатып алуга, шул исәптән импорт буенча, итчелек юнәлешендәге нәселле яшь мөгезле эре терлек сатып алуга, шул исәптән импорт буенча, итчелек юнәлешендәге нәселле үгезләр орлыкларын сатып алуга, шул исәптән импорт буенча, Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

а) Министрлык тарафыннан расланган форма буенча белешмә-исәпләмә;

б) товарлар өчен түләнгәнлеккә банктан өземтә һәм түләү поручениесе, түләүче банк раслаган аванс түләүләрен кертеп;

в) нәселле терлек үрчетүче оешма тарафыннан бирелгән килешү, счет-фактура, накладной яки гурт ведомосте, нәсел таныклыгы яки паспорт (ун баштан артыграк терлек сатып алынган очракта нәсел таныклыклары яки паспорт реестры тапшырыла);

г) фермада терлек һәм кош-кортның хәрәкәте турында хуҗалык эче хисабы;

д) 2015 елга рәсми статистика хисабы өчен нигез булып торган терлекчелекнең торышы турында мәгълүмат;

е) үзенең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү турында гариза.

Тапшырылган документлар күчермәләре авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан расланыла:

Министрлык:

а) субсидияләр алуга гаризаларны, алынган көнне, журналда терки, журнал битләренә номер сугылган һәм тегелгән, мөһер белән расланган, беркетелгән булырга тиеш;

б) бу Тәртипнең 7 пункты нигезендә тапшырылган документларны карап тикшерә. Документларны карап тикшерү срогы – гариза теркәтүгә алынганнан соң 15 эш көне.

Субсидия бирүдән баш тартуга нигезләр булып тора:

документларны тулысынча тапшырмау;

документларда тулы булмаган, ялган мәгълүматларның булуы;

бюджет йөкләмәләре лимитының булмавы.

8. Министрлык бюджет средстволарын баш бүлүче булып тора һәм Федераль казначылык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган үзенең лицевой счетыннан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең расчет счетларына, акча средстволарын бирү турында карар кабул ителгәннән соң 10 эш көне эчендә, акча средстволарын күчерүне хәл итә.

Министрлык, Министрлык тарафыннан расланылган форма буенча, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре белән субсидия бирү турында килешү (алга таба – Килешү) төзи, анда субсидияләр бирүнең мәҗбүри шарты булып алучыларның Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контрольлеге органнары тарафыннан субсидияләр алучыларның субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерүгә ризалык бирүе тора.

9. Бирелгән субсидияләр, бу Тәртиптә билгеләнгән аларны бирү максатларын һәм шартларын бозу, субсидияләрне максатчан файдаланмау яки субсидияләр алу өчен ялган мәгълүматлар һәм документлар тапшыру очраклары ачыкланганда, Министрлык таләбе алынганнан соң 60 көн эчендә федераль бюджет кеременә кире кайтарылырга тиеш.

10. Субсидияләр алу турында килешүләрдә күздә тотылган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр калдыклары субсидияләр алучылар тарафыннан, субсидияләр бирелгән елдан соң килгән елның 1 декабренә кадәр, федераль бюджет керемено кире кайтарылырга тиеш.

11. Бу Тәртипнең 9 һәм 10 пунктларында күрсәтелгән бюджет средстволарын федераль бюджет керемен ә ихтыярый рәвештә кире кайтарудан баш тарту очрагында, алар, закон нигезендә, мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.

12. Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контрольлеге органнары авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

13. Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык аларның җитәкчеләренә һәм баш бухгалтерларына йөкләнә. Закон бозучыларга карата закон нигезендә күздә тотылган җаваплылык чаралары кулланыла.

14. Бюджет средстволарыннан максатчан файдалануга Министрлык контрольлек итә.

ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 15.01.2016 ел, № 1/2-пр боерыгына № 8 кушымта

**2016 елда авыл хуҗалыгын иминиятләштерү килешүләре буенча иминиятләштерү премияләрен түләүгә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре чыгымнарының бер өлешен каплауга федераль бюджеттан субсидияләр бирү тәртибе**

1. Бу Тәртип авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш) үсемлекчелек өлкәсендә һәм терлекчелек өлкәсендә авыл хуҗалыгын иминиятләштерү килешүләре буенча иминиятләштерү премияләрен түләүгә субсидияләр (алга таба – субсидияләр, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре) бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр алуга авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләрен сайлап алуның критерийләре булып тора:

а) авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү;

б) авыл хуҗалыгы культураларының чәчүлек мәйданнарына, күп еллык агач мәйданнарына ия булу (авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең, дәүләт ярдәме белән хәл ителә торган авыл хуҗалыгы культуралары, виноград агачлары, җимеш, җиләк, чикләвек агачлары, колмак, чәй плантацияләре, күп еллык агачлар уңышын иминиятләштерү килешүләре буенча иминиятләштерү премияләрен түләүгә чыгымнарның бер өлешен каплаганда);

в) милектә һәм (яки) аренда хокукында терлекләргә һәм кош-кортка ия булу (дәүләт ярдәме белән хәл ителә торган, терлекләрне иминиятләштерү килешүләре буенча иминиятләштерү премияләрен түләүгә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләрнең чыгымнарының бер өлешен каплаганда).

3. Арбитраж суд тарафыннан субсидияләр алучыларга карата бөлгенлеккә төшү турында эш кузгатылганда, алар (алучылар) бу хакта, эш кузгатылган көнне, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) язмача хәбәр итәргә тиеш.

Субсидияләр үзләренә карата арбитраж суды тарафыннан бөлгенлеккә төшү тарафыннан эш кузгатылган авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә бирелми.

4. Субсидияләр авыл хуҗалыгын иминиятләштерү килешүе буенча исәпләнелгән иминиятләштерү премиясен түләүгә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре чыгымнарының бер өлешен каплауга бәйле максатларга бирелә:

а) үсемлекчелек өлкәсендә – түбәндәге вакыйгаларның килеп чыгуы аркасында авыл хуҗалыгы культуралары (бөртек, бөртекле-кузаклы, май, техник, терлек азыгы, карбыз-кавын, бәрәңге, яшелчә культуралары), виноград агачлары, җимеш, җиләк, чикләвек агачлары, колмак, чәй плантацияләре уңышын югалту, күп еллык агачларны (виноград агачлары, җимеш, яшелчә һәм чикләвек агачлары, колмак, чәй плантацияләре) югалту очрагында:

авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү өчен куркыныч тудырган табигать күренешләре (һаваның, туфракның корылыгы, туфракны киптерә торган җил, кырау, өшү, черү, боз сугу, тузан бураны, боз катламы хасил булу, су басу, туфракның кирәгеннән артык юешләнүе, көчле җил, ураган җиле, җир тетрәү, таулардан кар-пычрак ташкыны агып төшү, табигатьтә янгын чыгу) йогынтысы;

зарарлы организмнарның үтеп керүе һәм (яки) таралуы, мондый хәлләр эпифитотик төс алган очракта;

сугарыла торган җирләрдә, ябык грунтта үстерелә торган авыл хуҗалыгы культураларын иминиятләштергәндә табигать афәтләре аркасында электр, җылылык, су белән тәэмин итү системаларына зыян килү;

б) терлекчелек өлкәсендә – түбәндәге вакыйгаларның килеп чыгуы аркасында терлекләрне (мөгезле эре терлек (буйволлар, үгезләр, эш үгезләре, сыерлар, яков), мөгезле вак терлек (кәҗәләр, сарыклар), дуңгызлар, атлар, качырлар, ишәкләр, дөяләр, боланнар (мараллар, таплы боланнар, төньяк боланнары), кроликлар, мех өчен киекләр, йомырка сала торган һәм ит токымлы кош-корт (казлар, күркәләр, тавыклар, бытбылдыклар, үрдәкләр, мисыр тавыклары, бройлер чебиләре), умарталарның юкка чыгуы (һәлак булуы) очрагында:

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан исемлеккә кертелгән хайваннарның йогышлы авырулар аркасында массакүләм төстә агулануы;

Табигать афәте (яшен сугу, җир тетрәү, тузан бураны, ураган җиле, көчле кар, буран, су басу, таулардан кар, пычрак ташкыны агып төшү);

терлекләрне асрау шартлары электр, җылылык энергиясен, суны мәҗбүри файдалануны күздә тоткан очракта, табигать афәте аркасында электр, җылылык, су белән тәэмин итү системаларына зыян килү;

янгын чыгу.

5. Субсидияләр алу өчен Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

иминиятләштерү оешмасының расчет счетына субсидияләр күчерү турында гариза (алга таба – гариза);

авыл хуҗалыгын иминиятләштерү килешүе һәм түләү поручениесе авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан иминиятләштерү премиясенең 50 процентын түләгәнлекне раслаган башка докукмент нигезендә төзелгән субсидия күләме турында белешмә (алга таба – белешмә) (белешмә формасы һәм аны тапшыру сроклары Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан билгеләнелә);

авыл хуҗалыгын иминиятләштерү килешүе күчермәсе;

түләү порučениесе яки авыл хуҗалыгы иминиятләштерү килешүе буенча авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан иминиятләштерү премиясенең (иминиятләштерү взносы) 50 процентын түләгәнлеккә башка документ күчермәсе;

авыл хуҗалыгын иминиятләштерү килешүен төзегәндә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесенә иминиятләштерү оешмасы тарафыннан бирелгән, иминиятләштерү оешмасының түләүгә сәләтенең факттагы маржа күләменең нормативтагы күләмнән ким дигәндә 30 процентка артыграк булуы турында, иминиятләштерү оешмасының түләү сәләте хакында хисаптан өземтә, аның җитәкчесе раслаган, яисә иминиятләштерү оешмасы тарафыннан авыл хуҗалыгын иминиятләштерү килешүе буенча иминиятләштерү түләвенә кагылышлы куркыныч ихтималының бер өлешен яңадан иминиятләштерү турында мәгълүматтан торган документ, шул исәптән яңадан иминиятләштерүче оешманың (яңадан иминиятләштерүче оешмалар) атамасы, яңадан иминиятләштерүгә тапшырылган куркыныч (куркынычлар) ихтималы буенча иминиятләштерү түләвенең өлеше (күләме) турында мәгълүматлар, яңадан иминиятләштерү килешүе (килешүләр) реквизитлары (килешүне төзү датасы, номеры, яңадан иминиятләштерү формасы);

тапшырылган документлар күчермәләре авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан расланa.

Субсидияләр түбәндәге шартлар үтәлгәндә бирелә:

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе белән авыл хуҗалыгын иминиятләштерүне хәл итүгә лицензиягә ия булган һәм “Авыл хуҗалыгын иминиятләштерүе килешүләре буенча иминиятләштерү премияләрен түләүгә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында” 22 декабрь, 2012 ел, № 1371 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган авыл хуҗалыгын иминиятләштерү килешүләре буенча иминиятләштерү премияләрен түләүгә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре чыгымнарының бер өлешен каплауга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләренең 54 пункты нигезендә күздә тотылган таләпләргә җавап биргән иминиятләштерү оешмасы арасында килешү төзү;

б) “Авыл хуҗалыгын иминиятләштерү өлкәсендә дәүләт ярдәме турында һәм “Авыл хуҗалыгын үстерү турында” Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында” 25 июль, 2011 ел, № 260-ФЗ Федераль законның 6 статьясында күздә тотылган, авыл хуҗалыгын иминиятләштерү планында (алга таба – авыл хуҗалыгын иминиятләштерү планы), – авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан авыл хуҗалыгы культуралары һәм күп еллык агачлар үстерелә торган җир кишәрлекләренең бөтен мәйданында – авыл хуҗалыгы культуралары, күп еллык агачлар уңышына карата авыл хуҗалыгын иминиятләштерү килешүен төзү;

в) тиешле елга авыл хуҗалыгын иминиятләштерү планында күрсәтелгән терлекләргә карата авыл хуҗалыгын иминиятләштерү килешүен төзү – авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесенең билгеле бер төрдәге барлык төрләренә;

г) түбәндәге срокларда авыл хуҗалыгын иминиятләштерү килешүен төзү:

авыл хуҗалыгы культураларына карата, күп еллык агачлардан тыш, – килешү төзүнең ахыргы срогы – аларны чәчү, утырту тәмамланганнан соң 15 календарь көне;

күп еллык агачларга карата – аларның үсеш чоры (кышкы йокыда булу чоры) туктаганчы;

терлекләргә карата – кимендә бер еллык срокка;

д) авыл хуҗалыгын иминиятләштерү килешүенең үз көченә керүе һәм авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан әлеге килешү буенча исәпләнелгән иминиятләштерү процентын түләү;

е) авыл хуҗалыгын иминиятләштерү килешүендә килешүнең гамәлдә булу срогы тәмамланганчы туктатылмавы турында шартның күздә тотылуы, Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 958 нче статьясында күздә тотылган очрактан тыш;

ж) авыл хуҗалыгын иминиятләштерү килешүендә авыл хуҗалыгы культурасы уңышының, күп еллык агачлар мәйданының, терлекләрнең кимендә 80 проценты күләмендә иминиятләштерү суммасын билгеләү;

з) авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесенең (иминиятләштерелгән зат) авыл хуҗалыгын иминиятләштерү килешүе буенча иминиятләштерү суммасының 40 процентыннан артып китмәгән күләмдә авыл хуҗалыгы куркынычлары ихтималын иминиятләштерүдә катнашуы;

и) иминиятләштерелгән затларга һәм керем алучыларга иминиятләштерү һәм компенсацияләә түләүләрен хәл итү өчен турыдан-туры билгеләнгән һәм иминиятләштерү тарифларын исәпләүдә кулланыла торган кимендә 80 процент күләмендә иминиятләштерү премиясен билгеләү;

к) Россия Федерациясе Финанс министрлыгы белән килештереп Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан расланган, авыл хуҗалыгы культурасы куышын югалтуның, күп еллык агачларны югалтуның, терлекләрне югалтуның (һәлак булу) иминиятләштерү бәясен һәм күләмен билгеләү методикаларын куллану;

л) тиешле елга авыл хуҗалыгын иминиятләштерү планы нигезендә, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы белән килештереп, Россия Федерациясе авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан билгеләнгән субсидияләр күләмен исәпләү өчен ставкалар куллану.

Гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылган иминиятләштерү килешүләре буенча авыл хуҗалыгын иминиятләштерү килешүе буенча иминиятләштерү премиясен түләүгә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре чыгымнарының бер өлешен каплау хәл ителми, Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 958 нче статьясында күздә тотылган иминиятләштерү килешүләрен туктату очрагыннан тыш.

Гамәлдә булуы Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 958 нче статьясы нигезендә туктатылган авыл хуҗалыгын иминиятләштерү килешүләре

буенча иминиятләштерү премиясен түләүгә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре чыгымнарының бер өлешен каплау авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе түләгән һәм иминиятләштерелгән зат тарафыннан кире кайтарылмаган иминиятләштерү премиясе өлешенә пропорциональ рәвештә хәл ителә.

7. Министрлык:

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең иминиятләштерү оешмасының расчеәт счетына субсидияләр күчерү турында гаризаларын, алынган көнне, журналда терки, журнал битләренә номер сугылган һәм тегелгән, Министрлык мөһере белән расланган-беркетелгән булырга тиеш, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан тапшырылган документларны тикшерә һәм, гаризаны теркәүгә алганнан соң 10 эш көненнән артмаган срокта, гаризаны карап тикшерүгә кабул итү яки карап тикшерүгә кабул итүдән баш тарту турында карар кабул итә, һәм авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесенә тиешле уведомление җибәрә, яки гаризаны карап тикшерүгә кабул итүдән булдыра;

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан тапшырылган документларны, гаризаны карап тикшерүгә кабул итү турында язмача уведомление булдырылган көннән соң 10 эш көненнән дә артмаган срокта субсидия алу өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан тапшырылган документларны карый;

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесенә субсидия бирүдән баш тарту очрагында, теркәүгә алу журналында тиешенчә язып куя, шул ук вакытта мөрәҗәгатьне карап тикшерүгә кабул итү турында язмача уведомление булдырылган көннән соң 10 эш көненнән дә артмаган срокта авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесенә тиешле язмача уведомление җибәрә;

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесенә субсидия бирүдән баш тарту очрагында авыл хуҗалыгы товар җитештерүче тарафыннан тапшырылган субсидия алу өчен кирәкле документларны, әлеге документлар субсидияләр алу өчен билгеләнгән таләпләргә туры китерелгәннән соң, кабат карап тикшерә;

Министрлык тарафыннан расланылган форма буенча, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре белән субсидия бирү турында килешү (алга таба – Килешү) төзи, анда субсидияләр бирүнең мәҗбүри шарты булып алучыларның Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контрольлеге органнары тарафыннан субсидияләр алучыларның субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерүгә ризалык бирүе тора.

Субсидия бирүдән баш тартуга нигезләр булып тора:

документларны тулысынча тапшырмау;

документларда тулы булмаган, ялган мәгълүматларның булуы;

бюджет йөкләмәләре лимитының булмавы;

Россия Банкы тарафыннан тиешле карар кабул ителгән көннән соң субсидияләр күчерү көненә, иминиятләштерү оешмасының иминиятләштерү эшчәнлеген яки авыл хуҗалыгын иминияләштерү төре буенча эшчәнлеген (уңышны, авыл хуҗалыгы культураларын, күп еллык агачларны, терлекләрне иминиятләштерү) туктатып тору, туктату яки лицензиясен кире алу.

Субсидия бирүдән баш тартуга законда билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерелергә мөмкин.

8. Министрлык бюджет средстволарын баш бүлүче булып тора һәм Федераль казначылык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган үзенең лицевой счетыннан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең расчет счетларына, акча средстволарын бирү турында карар кабул ителгәннән соң 10 эш көне эчендә, акча средстволарын күчерүне хәл итә.

9. Бирелгән субсидияләр, бу Тәртиптә билгеләнгән аларны бирү максатларын һәм шартларын бозу, субсидияләрне максатчан файдаланмау яки субсидияләр алу өчен ялган мәгълүматлар һәм документлар тапшыру очраклары ачыкланганда, Министрлык таләбе алынганнан соң 60 көн эчендә федераль бюджет керемenә кире кайтарылырга тиеш.

10. Субсидияләр алу турында килешүләрдә күздә тотылган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр калдыклары субсидияләр алучылар тарафыннан, субсидияләр бирелгән елдан соң килгән елның 1 декабренә кадәр, федераль бюджет кеременә кире кайтарылырга тиеш.

11. Бу Тәртипнең 9 һәм 10 пунктларында күрсәтелгән бюджет средстволарын федераль бюджет кеременә ихтыярый рәвештә кире кайтарудан баш тарту очрагында, алар, закон нигезендә, мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.

12. Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контрольлеге органнары авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

13. Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан Министрлыкка тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык аларның җитәкчеләренә һәм баш бухгалтерларына йөкләнә. Закон бозучыларга карата закон нигезендә күздә тотылган җаваплылык чаралары кулланыла.

14. Бюджет средстволарыннан максатчан файдалануга Министрлык контрольлек итә.